ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга, 422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шилангы авылы, 422577

Тел.: (84379) 32-7-48, факс: (84379) 32-7-02.

02.04.2024 № 21

На №______________ от________________

«Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек авылы гражданнар җыенының 28.10 2023 ел № 10 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 90 тәртибенең 2 пункты (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 апреленә гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2024 елның 13 апреленә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Берек авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 октябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл төзү).

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Йорт яны территориядә гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча

уздырырга: Берек авылы, Үзәк  урамы, 17 йорт 10:00 сәгатьтә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В. В. Майоров